СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423740,село Актаныш, проспект Ленина,дом 58,тел.3-44-40

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКТАНЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
423740, Актаныш авылы, Ленин проспекты, 58 нче йорт, тел.3-44-40

# КАРАР

№ 15 «07» июль 2020 ел

**Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлегенең кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында**

Норматив хокукый актларны гамәлдәге кануннарга туры китерү максатларында Актаныш муниципаль районының Актаныш авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районының Актаныш авыл җирлеге Советының «Актаныш муниципаль районының Актаныш авыл җирлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы муниципаль вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында» 01 август 2007 елгы 17/04 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а. 1 нче кушымтаның 9 пунктындагы 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «5) индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ, моңа хезмәт шартнамәсенең (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклары керми;».

2. Актаныш муниципаль районының Актаныш авыл җирлеге Советының «Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә яңа редакциядә» 11 сентябрь 2017елгы 22 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а. Нигезләмәнең 3.3 пунктының 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «6) индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ, моңа хезмәт шартнамәсенең (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклары керми;».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Актаныш авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Актаныш авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Совет рәисе,
Актаныш авыл җирлеге Башлыгы Э.Н.Фәттахов